## Кайсыгызның кулы җылы?

Дөнья мине
Үзгәртте:
Еламаска өйрәтте.
Күлмәк җиңен ертасымы? –
Бәйлисе бар
Йөрәкне.

Сугышлардан замана
Туктап торган арада,
Яраларны ямаштырып
Ята идем
Далада:

- Кайт!.. – дип, хатлар
килделәр.
Юллар... озын иделәр...
Кайттым.
- Бусы – алкалары,
Бусы – кабере...- диделәр.

Әгәр тагын килсәләр:
- Сау! – дип хәбәр бирсәләр,
Вулканнарга керер идем,
Шундадыр ул... дисәләр.

Бирде дөнья кирәкне,
Еламаска өйрәтте...
Кайсыгызның кулы җылы? –
Бәйлисе бар йөрәкне...

ХӘСӘН ТУФАН.

## *ЛИРИК ШИГЫРЬ АНАЛИЗЛАУ ПЛАНЫ*.

**1.Язылу вакыты. Реаль – биографик һәм фактологик аңлатмалар.**
**2.Жанры (пейзаж лирикасы, гражданлык лирикасы, сәяси лирика, күңел лирикасы,фәлсәфи лирика)**
**3.Лирик геройга бәя. Аның сурәтләнгәннәргә мөнәсәбәте, кичереше, фикере.**
**4.Тема, төп эчтәлек.**
**5.Хисләр бирелеше, аларның гәүдәләнеше, үсеш – үзгәреше.**
**6.Төп образлар, аларның әһәмияте, яңалыгы.**
**7.Сөйләм үзенчәлекләре, сурәтләү чаралары.**
**8.Әсәрнең төзелеше.**
**9.Шигырь төзелеше ягыннан бәя. Ритм һәм рифма.**

## Лирика

*Пейзаж лирикасы*
*Гражданлык*
*Лирикасы*
*Сәяси лирика*
*Күңел лирикасы*
*Фәлсәфи лирика*

## Эпос

*Хикәя*
*Очерк*
*Хикәят*
*Новелла*
*Әкият*
*Повесть*
*Роман*

## Драма

*Трагедия*
*Комедия*
*Драма*

**ЧАГЫШТЫРУ** – НИНДИ ДӘ БУЛСА КҮРЕНЕШНЕ АҢА ОХШАШ ЯГЫ БУЛГАН ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ БЕЛӘН ЧАГЫШТЫРЫП СЫЙФАТЛАУ – ОХШАТУ.

Нарасый **Кояш**! Син дә
**бала кебек гамьсез.**
(Р. Гаташ)

**Мета́фора** — күренешләрнең охшашлыгына яки каршылыгына нигезләнгән яшерен чагыштыру. Мондый тропта *кебек*, *сыман*, *шикелле* кебек ярдәмче сүзләр, кушымчалар төшеп кала, кайчак чагыштырыла торган күренешләрнең берсе генә әйтелә.

**Тәңкә карлар** ява,
Ап-ак карлар ...
(Һ. Такташ)

**ЭПИТЕТ** - әдәби ачыклау ярдәмендә образ тудыручы сурәтләү чарасы.

Бер сәгать кенә моннан әүвәл явып киткән **җиңел яңгыр** шәһәр урамнарының тузанын баскан...(Ф.Ә.)

**Гипербола** – чиктән тыш арттыру.

Җиде кат җиргәчә нәфрәтем.
Җиде кат күккәчә шатлыгым.(Р.Ф.)

**Литота** – әдәби кечерәйтү.

**Зәгыйфь кырмыскамын мин** юлда яткан...(Дәрдемәнд)